КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 10 октябрь г.Казань № 875

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 30 июнь, 514 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 30 июнь, 514 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 5 август, 680 нче; 2021 ел, 31 август, 788 нче; 2021 ел, 7 сентябрь, 835 нче; 2021 ел, 25 ноябрь, 1127 нче; 2021 ел, 22 декабрь, 1266 нчы; 2022 ел, 15 март, 240 нчы; 2022 ел, 22 июль, 707 нче; 2022 ел, 16 сентябрь, 1009 нчы; 2022 ел, 13 декабрь, 1319 нчы; 2022 ел, 21 декабрь, 1389 нчы; 2023 ел, 21 февраль, 168 нче; 2023 ел, 4 июль, 786 нчы; 2023 ел, 9 август, 961 нче; 2023 ел, 5 октябрь, 1239 нчы; 2024 ел, 4 март, 119 нчы; 2024 ел, 17 апрель, 258 нче; 2024 ел, 10 май, 317 нче; 2024 ел, 5 август, 622 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Агросәнәгать комплексы объектларын төзүгә һәм (яисә) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау, шулай ук федераль бюджеттан финанслаша торган сөт продукциясенең аерым төрләрен мәҗбүри маркировкалауны гамәлгә кертү өчен маркировка җиһазлары сатып алу һәм аларны сәнәгатьтә файдалануга кертү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен»;

әлеге карарга Агросәнәгать комплексы объектларын төзүгә һәм (яисә) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау, шулай ук федераль бюджеттан финанслаша торган сөт продукциясенең аерым төрләрен мәҗбүри маркировкалауны гамәлгә кертү өчен маркировка җиһазлары сатып алу һәм аларны сәнәгатьтә файдалануга кертү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин